| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2020 Баулы шәһәре № 20

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә

К А Р А Р И Т Ә М:

1. Исергәп авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышу буенча ачык тыңлауларны 2020 елның 11 мартына 10.00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 нче йорт, 200 ном каб.

2. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы итеп Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләргә.

3. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы Р. И. Хасиятуллинага тәэмин итәргә:

- ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү турындагы законнар, муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне;

- кызыксынган затларга ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирүне;

- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм халыкка җиткерүне.

4. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20 йорт, 101нче каб. адресы буенча кертелергә мөмкин (эш көннәрендә 9: 00 дән 15: 00 сәгатькә кадәр, тел. 6-07-19).

5. Кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

6. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы Башлыгының
2020 елның «12» 02
кабул ителгән
20 нче карарына
кушымта

Кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм
карау буенча эшче төркем
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Гозәеров<br>Ильяс Исмәгыйль улы | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем җитәкчесе; |
| Каһиров<br>Радик Әхмәтсайфи улы | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы; |
| Михайлова<br>Алина Анатольевна | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе; |
| Хасиятуллина<br>Роза Ильяс кызы | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы. |